**ЛАТЫЙПОВ РАШАТ ВАГЫЙЗ УЛЫ**



2018 елда Яшел Үзән медицина училищесы директоры вазыйфасына Латыйпов Рашат Вагыйз улы билгеләнде.

Рашат Вагыйз улы 1964 елның 30 апрелендә Татарстан Республикасының Буа районы Сарсаз авылында туган.

1987 елда «Дәвалау эше» белгечлеге буенча Казан дәүләт медицина университетын тәмамлаган. 1988 елда «Оториноларингология» белгечлеге буенча Куйбышев медицина университетының интернатурасын, 1997 елда Казан дәүләт медицина академиясенең аспирантурасын тәмамлый.

**Хезмәт эшчәнлеге:**

1988-1999 елларда – табиб-оториноларинголог;

2000-2004 елларда – Яшел Үзән үзәк район хастаханәсенең баш табибы;

2004-2007 елларда – Казан шәһәре Башкарма комитетының Сәламәтлек саклау идарәсенең Сәламәтлек саклау бүлеге;

2007-2014 елларда – Сәламәтлек саклау муниципаль учреждениесенең «16 нчы шәһәр хастаханәсе» баш табиб урынбасары;

2014 ел – хәзерге вакытта – КДМУның оториноларингология кафедрасы доценты.

Медицина фәннәре кандидаты.

Татарстан Республикасының атказанган табибы.

«РФ Сәламәтлек саклау отличнигы» билгесе, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнгән.

Яшел Үзән медицина училищесы директоры булып эшләү дәверендә коллектив алдына амбициоз максатлар, аерым алганда, һөнәргә әзерләү белгечлекләрен киңәйтү максаты куелды. Ике ел эчендә матди-техник база шактый яхшырды, лицензияләнгән медицина кабинеты ачылды һәм анда эшләүче фельдшер вазифасы кертелде, спорт һәм актлар залларына, ашханәгә ремонт ясалды, уку җиһазлары яңартылды, бинасын һәм тулай торакны террорчылыкка каршы яклау буенча зур эш башкарылды (тулай торакта һәм уку корпусында турникетлар, училище бинасында һәм аның периметры буенча тышкы якта видеокүзәтү урнаштырылды). «Фармация», «Социаль хезмәткәр», «Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы» яңа

белгечлекләре лицензияләнде. Училищеда укучылар контингенты сизелерлек артты.

2021 елда Латыйпов Р. В. инициативасы белән Яшел Үзән медицина училищесы «Дәвалау эше» компетенциясе буенча «Яшь профессионаллар» Региональ чемпионатын үткәрү мәйданчыгына әверелә.